СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 8-32 от « 29 » марта 2019 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының
15.10.2015 ел, 4-2 санлы карары белән расланган
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль
хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

“Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 15 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү турында” 2018 елның 20 декабрендәге 106 –ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы , “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы
к а р а р к а б у л и т т е:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 15.10.2015 ел, 4-2 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (12.11.2016 ел, № 3-12, 12.05.2017 ел, № 8-16, 26.07.2017 ел, № 4-18, 13.11.2017 ел, №4-19, 29.06.2018 ел, №10-27, 03.09.2018 ел, № 8-28, 19.11.2018 ел, № 11-29 үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 7 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 7.4. пунктчасы белән тулыландырырга:

“7.4. Җитәкче булып эшләүче муниципаль хезмәткәр, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау максатларында, күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында муниципаль берәмлекнең әлеге җирле үзидарә органының һөнәр берлеге органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатен кайгырта алмый.”

1.2. 8.1. пунктында:

“ сәяси партия белән;” сүзләреннән соң “түләүсез нигездә һөнәр берлеге органы, шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында төзелгән башлангыч һөнәр берлегенең сайланулы органыннан “ сүзләре белән тулыландырырга.;

“бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылыр кооперативы,” сүзләрен төшереп калдырырга;

000018

“сәяси партиядән башка” сүзләреннән соң һәм һөнәр берлеге органыннан шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында төзелгән башлангыч һөнәр берлегенең сайланулы органыннан” сүзләрен өстәргә.

2.Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов